Сабантуй

Рамилә Уваева



Россия буенча

# МИЛЛИ СӘЯХӘТ

ББК 74.200.58 (2Рос=Тат)
УДК 821.512.145
У18

***Рәссамы – Надежда Нечаева***

**Уваева Р.К.**

У18 Россия буенча милли сәяхәт. – Казан : «Сабантуй» журналы редакциясе, 2022. – 36 б. : рәс. б-н.

Справочное издание
Для детей дошкольного и школьного возраста
Автор-составитель
**Уваева** Рамиля Камилевна

## Национальное путешествие по России

Казань. Редакция журнала «Сабантуй». 2022
***На татарском языке***

Белешмә басма
Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балалар өчен
Автор-төзүчесе
**Уваева** Рамилә Камил кызы

## Россия буенча милли сәяхәт

Мөхәррире ***З.З.Фәйзуллина***
Бизәлеш мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы ***Э.Яфизова***
Корректоры ***Г.Ф.Хәйдәрова***
6+ Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010г. №436-ФЗ
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.02.2022.
Форматы 84×108/16. Шартлы басма табагы 2,25.
Тиражы 1000 данә.
Заказ № 0098.

«Татмедиа» АҖ филиалы
«Салават күпере» журналы редакциясе».
Казан, Декабристлар ур., 2.
Тел.: (843) 222-05-46.
www.sabantuyjournal.ru
e-mail: sabantui@bk.ru

Җаваплылыгы чикләнгән «Киров өлкә типографиясе»ндә басылды.
Адресы: 610004, Киров өлкәсе, Киров шәһәре, Ленин урамы, 2В йорт.
Тел/факс: (8332) 38-34-34. www.printkirov.ru

©«Сабантуй» журналы, 2022
©Уваева Р.К., 2022

# Руслар







МИЛЛИ РИЗЫКЛАР. Щи, уха, рассольник, окрошка, пилмән, белен.

ХАЛЫК САНЫ. Дөньяда – 130 миллионнан артык, Россиядә – 112 миллион чамасы, Татарстанда – 1,5 миллион тирәсе.

ТЕЛ. Ә син беләидеңме, рус телендәге «деньги» сүзе «тәңкә»дән алынган. Билгеле булганча, ул татар телендә акча дигәнне аңлата. Әби-бабайлар әле хәзер дә «биш сум» урынына «биш тәңкә» дияргә мөмкин.

КИЕМ. Ир-атларда – картуз, кыек якалы күлмәк, пута, ыштан, кафтан. Хатын-кызларда – кокошник, күлмәк, сарафан.

**Россиядә 190 нан артык милләт вәкиле яши. Сәяхәтебезне нәкъ менә рус милләтеннән башлавыбызның сәбәбе бик гади. Бу — Россиядәге, алай гына да түгел, Европадагы иң күпсанлы халык.**

АЛАР – МИЛЛӘТ ГОРУРЛЫГЫ. Александр Пушкин, Фёдор Достоевский, Лев Толстой, Дмитрий Менделеев, Пётр Чайковский, Иван Павлов, Сергей Королёв һәм башка бик күп танылган шәхесләр.






**Бер гасыр яшә – бер гасыр укы.**
Рус халык мәкале.

МИЛЛИ БӘЙРӘМ. Русларның милли бәйрәмнәре христиан дине белән тыгыз бәйләнгән. Кайберсен христиан чиркәве үз йөкласына әверелдергән. Шундыйларның берсе — май чабу (масленица) бәйрәме. Аны атна буе билгеләп үтәләр. Бу атнада көн саен блен пешерелә. Блен — кояш символы. Кыш үтеп, яз җитүне аңлата. Май чабу — кышны озату бәйрәме ул.



## Бөек Новгород

Рус милләте белән танышуыбызны Новгород өлкәсендә дәвам итәбез. Россиянең башкаласы, руслар күпләп яшәгән шәһәр Мәскәү бит, диярсең. Дөрес! Ләкин Мәскәү соңгы бер гасырда гына башкала булып тора. Ә менә Бөек Новгород — рус дәүләтенең беренче башкаласы (Иске Ладога крепостен исәпкә алмаганда). Тарихчылар фикеренчә, Рюрик кенәзлек итүен нәкъ менә монда башлаган.

Бөек Новгород 859 нчы елда төзелгән. Борынгы чорда ук бу шәһәр Кремлен таш диварлар саклаган. Новгород иң мөһим сәүдә үзәге булган.

Күз алдыңа китерәсеңме, кала сәүдәгәрләре Лондон белән Парижны «пычрак авыллар» дип йөрткән. Чөнки Новгородта Европа шәһәрләреннән алда ук юл түши башлаганнар. Россия үсешенә зур өлеш керткәне өчен, бу шәһәрне «бөек» дип атаганнар да!

Бүген Бөек Новгородта 400 еллык агач өйләрне, бик борынгы чиркәү һәм монастырьларны, Новгород ныгытмасының саклану манараларын күрергә була. Ә шәһәрнең иң билгеле урыны — София соборы. Ул — Россиядәге иң борынгы гыйбадәтханәләрнең берсе.